Татарстан Республикасы

# ЗАКОНЫ

**«Татарстан Республикасында суд участокларын төзү һәм җәмәгать судьялары урыннарын булдыру турында» Татарстан Республикасы Законының 2 статьясына үзгәреш кертү хакында**

Татарстан Республикасы
Дәүләт Советы тарафыннан
2010 елның 23 сентябрендә
кабул ителде

**1 статья**

«Татарстан Республикасында суд участокларын төзү һәм җәмәгать судьялары урыннарын булдыру турында» 2000 елның 31 маендагы 177 номерлы Татарстан Республикасы Законының 2 статьясына (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 2000, № 6 (5); 2007, № 11), аны яңа редакциядә бәян итеп, үзгәреш кертергә:

«**2 статья.** Татарстан Республикасы районнарында һәм шәһәрләрендә җәмәгать судьяларының суд участоклары чикләре, суд участогындагы халык саны исәбеннән чыгып, Татарстан Республикасы законнары тарафыннан билгеләнә һәм үзгәртелә.».

**2 статья**

Киләчәктә җәмәгать судьяларының суд участоклары чикләрен билгеләү турында Татарстан Республикасы законнары кабул ителгәнче Татарстан Республикасы җәмәгать судьяларының суд участоклары чикләре турында элегрәк кабул ителгән Татарстан Республикасы норматив-хокукый актлары кулланыла.

**3 статья**

Әлеге Закон рәсми басылып чыккан көненнән соң 10 көн узгач үз көченә керә.

Татарстан Республикасы
Президенты Р.Н. Миңнеханов

ГОМУМИ БҮЛЕК ОБЩИЙ ОТДЕЛ

Казан, Кремль
2010 елның 14 октябре
№ 76-ТРЗ